КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 27 гыйнвар г.Казань № 37

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2029 елга кадәр иҗтимагый инфраструктура, социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителүнең социаль гарантияләре дәрәҗәсен билгеләү турында» 2009 ел, 26 гыйнвар, 42 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2029 елга кадәр иҗтимагый инфраструктура, социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителүнең социаль гарантияләре дәрәҗәсен билгеләү турында» 2009 ел, 26 гыйнвар, 42 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 20 октябрь, 828 нче; 2012 ел, 7 февраль, 89 нчы; 2012 ел, 10 ноябрь, 977 нче; 2013 ел, 19 март, 191 нче; 2013 ел, 30 май, 361 нче; 2014 ел, 8 июль, 465 нче; 2016 ел, 18 ноябрь, 846 нчы; 2019 ел, 1 февраль, 61 нче; 2019 ел, 28 август, 721 нче; 2023 ел, 7 август, 950 нче; 2023 ел, 30 декабрь, 1768 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), әлеге карарга теркәлгән кушымтаның 4 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

| «4. Медицина оешмалары | | |
|---|---|---|
| 4.1. Фельдшер-акушерлык пункты | үзәк район хастаханәсенең структур бүлекчәләре | беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүче якындагы медицина оешма-сыннан 6 км ераклыкта урнашуын исәпкә алып, халкы 100 кешедән 2 000 кешегә кадәр булган торак пунктына 1 |
| 4.2. Поликлиника | оешмалар | 51 – 100 мең кешегә 1 |
| | структур бүлекчәләр | 10 – 50 мең кешегә 1 |

| | | |
|---|---|---|
| 4.3. Поликлиника составындагы хатын-кызлар консультациясе | структур бүлекчәләр | 20 – 100 мең кешегә 1 |
| 4.4. Балалар поликлиникасы | оешмалар | 31 – 100 мең балага 1 |
| | структур бүлекчәләр | 20 – 30 мең балага 1 |
| 4.5. Стоматология поликлиникасы | оешмалар | 100 мең кешегә 1 |
| 4.6. Стоматология кабинеты (бүлеге) | оешмалар | 20 – 99 мең кешегә 1 |
| 4.7. Балалар стоматология поликлиникасы | оешмалар | 20 – 50 мең балага 1 |
| 4.8. Участок хастаханәсе | үзәк район хастаханәсенең структур бүлекчәләре | 5 – 20 мең кешегә 1 |
| 4.9. Шәһәр хастаханәсе | оешмалар | Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булган шәһәр округлары һәм шәһәр җирлекләре өчен 100 – 300 мең кешегә 1. Транспорт белән барып җитү мөмкинлеге 60 минут |
| 4.10. Шәһәр балалар хастаханәсе | оешмалар | 20 – 200 мең балага 1. Транспорт белән барып җитү мөмкинлеге 60 минут |
| 4.11. Балалар бүлеге | структур бүлекчәләр | 5 – 20 мең балага 1. Транспорт белән барып җитү мөмкинлеге 60 минут |
| 4.12. Үзәк район хастаханәсе | оешмалар | муниципаль районга 1. Транспорт белән барып җитү мөмкинлеге 60 минут |
| 4.13. Амбулатория, шул исәптән табиблар амбулаториясе | үзәк район хастаханәсенең структур бүлекчәләре | 2 – 10 мең кешегә 1 |
| 4.14. Йогышлы авырулар хастаханәсе | оешмалар | 500 – 1 000 мең кешегә 1 |
| 4.15. Балалар йогышлы авырулар бүлеге | структур бүлекчәләр | 100 – 500 мең балага 1 |
| 4.16. Республика хастаханәсе | оешмалар | республикага 1 |
| 4.17. Республика балалар хастаханәсе | оешмалар | республикага 1 |
| 4.18. Психоневрология хастаханәсе | филиаллары белән оешмалар | республикага 1 |
| 4.19. Наркология диспансеры | оешмалар | республикага 1 |
| 4.20. Тире-венерология диспансеры | оешмалар | республикага 1 |
| 4.21. Туберкулезга каршы диспансер | оешмалар | республикага 1 |
| 4.22. Онкология диансеры | филиаллары белән оешмалар | республикага 1 |
| 4.23. Табиблар физкультурасы диспансеры | оешмалар | республикага 1 |
| 4.24. Эндокринология диспансеры | оешмалар | республикага 1 |
| 4.25. Республика офтальмология хастаханәсе | филиаллары белән оешмалар | республикага 1 |

| | | |
|---|---|---|
| 4.26. Хоспис | оешмалар яисә структур бүлекчәләр | 1 400 мең кешегә 1. Бүлекнең тәкъдим ителә торган куәте иң күбе 30 койка |
| 4.27. Медик-социаль экспертиза бюросы | оешмалар | республикага 1 |
| 4.28. Суд-медицина экспертизасы бюросы | филиаллары белән оешмалар | республикага 1 |
| 4.29. Клиника-диагностика лабораториясе | структур бүлекчәләр | 20 мең кешегә 1 |
| 4.30. Бактериология лабораториясе, шул исәптән туберкулез диагностикасы буенча | структур бүлекчәләр | 170 мең кешегә 1 |
| 4.31. СПИДны һәм йогышлы авыруларны профилактикалау һәм аларга каршы көрәш үзәге | оешмалар | республикага 1 |
| 4.32. Кан салу станциясе | филиаллары белән оешмалар | республикага 1 |
| 4.33. Диспетчерлык үзәге | оешмалар | республикага 1 |
| 4.34. «Резерв» мобилизация резервлары медицина үзәге | оешмалар | республикага 1 |
| 4.35. Медицина китапханә-мәгълүмат үзәге | оешмалар | республикага 1 |
| 4.36. Медицина мәгълүмат-аналитика үзәге | оешмалар | республикага 1 |
| 4.37. Ашыгыч медицина ярдәме станциясе | оешмада, структур бүлекчәдә гомумпрофильле күчмә бригадалар саны | хезмәт күрсәтү радиусының озынлыгы 20 км га тигез булган, халык күпләп яши торган (халык тыгыз урнашкан) районнарда:<br>4 мең хезмәт күрсәтелә торган олыларга 1;<br>4 мең хезмәт күрсәтелә торган балаларга 1; |
| | оешмада, структур бүлекчәдә махсуслаштырылган күчмә бригадалар саны | һәр 100 мең хезмәт күрсәтелә торган кешегә 1 |
| | 1 000 кешегә ашыгыч ярдәм чакырулар | гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү дәүләт гарантияләренең территориаль программасы белән билгеләнгән бер кешегә (бер иминләштерелгән зат) исәпләгәндә медицина ярдәме күләмнәре, шулай ук медицина ярдәме күрсәтү тәртипләре һәм медицина ярдәме стандартлары дәрәҗәсендә |
| ашыгыч ярдәм бүлеге | структур бүлекчәләр | 2023 елның 1 гыйнварына карата факттагы тәэмин ителеш дәрәҗәсендә |

| | | |
|---|---|---|
| 4.38. Амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтүче ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү бүлекләре (пунктлары, кабинетлары) | структур бүлекчәләрдә кабинетлар саны | 40 мең кешегә 1 |
| 4.39. Даруханәләр, даруханә пунктлары | даруханә челтәре оешмалары | 3 мең кешегә 1. Авыл торак пунктларында транспорт белән барып җитү мөмкинлеге 30 минут |
| 4.40. Шифаханәләр, в том числе:<br>олылар өчен шифаханәләр;<br>балалар өчен, ата-аналар белән балалар өчен шифаханәләр;<br>шифаханә-профилакториеләр | койка-урыннар | 1 мең кешегә 4,5кә кадәр». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин